РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

09.04.2026 405-п

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 05 мартындагы 359-п номерлы карары белән Саба муниципаль районында коткару хезмәтләрен формалаштыру һәм алар эшчәнлеген башкару тәртибе һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының гражданнар оборонасы штабы турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

2025 елның 23 июлендәге 240-ФЗ номерлы «Гражданнар оборонасы турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

**1.** Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 05 мартындагы №359-п номерлы «Саба муниципаль районында гражданнар оборонасы чараларын тәэмин итү һәм коткару хезмәтләрен булдыру турында» карары белән расланган Саба муниципаль районында коткару хезмәтләрен формалаштыру һәм аларның эшчәнлеген башкару Тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1.1.** 1.1 пунктта «хәрби хәрәкәтләр алып барганда яисә шушы гамәлләр нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр һәм террорчылык актлары нәтиҗәләрен бетергәндә» сүзләрен «мобилизация чорында, хәрби хәл гамәлдә булган чорда, сугыш вакытында»сүзләренә алмаштырырга;

**1.2.** 3.2.4 нче пунктның өченче абзацында «хәрби хәрәкәтләр алып барганда яисә шушы гамәлләр нәтиҗәсендә» сүзләрен «мобилизация чорында, хәрби хәл гамәлдә булган чорда, сугыш вакытында» сүзләренә алмаштырырга.;

**2.** Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 05 мартындагы 359-п номерлы «Саба муниципаль районында гражданнар оборонасы чараларын тәэмин итү һәм коткару хезмәтләрен булдыру турында» карары белән расланган Саба муниципаль районында гражданнар оборонасы чараларын тәэмин итү турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертелергә:

**2.1.** 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Гражданнар оборонасы буенча мобилизация чорында, хәрби хәл гамәлдә булган чорда, сугыш вакытында барлыкка килә торган куркынычлар турында халыкка хәбәр итүгә бәйле бурычларны хәл итү максатларында гамәлгә ашырыла торган төп чаралар булып түбәндәгеләр тора:

халыкка хәбәр итү системаларын, шул исәптән муниципаль һәм локаль халыкка хәбәр итү системаларын булдыру, реконструкцияләү һәм файдалануга даими әзерлек халәтендә тоту;

кешеләр күпләп була торган урыннарда халыкка хәбәр итү һәм мәгълүмат бирүнең махсуслаштырылган техник чараларын урнаштыру;

Россия Федерациясенең бердәм электр элемтәсе челтәре чараларыннан, радио, Чыбыклы һәм телевидение тапшырулары челтәрләреннән һәм чараларыннан, шулай ук мәгълүмат тапшыруның башка техник чараларыннан комплекслы файдалану;

мәгълүмат җыю һәм аны алмашу.»;

**2.2.** 6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Халыкны эвакуацияләүгә, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне куркынычсыз районнарга саклауга бәйле бурычларны хәл итү максатларында гамәлгә ашырыла торган гражданнар оборонасы буенча төп чаралар булып түбәндәгеләр тора:

- халыкны эвакуацияләүне планлаштыруны, әзерләүне һәм уздыруны, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне яклауны оештыру;

- халыкны урнаштыру, эвакуацияләнергә тиешле матди һәм мәдәни кыйммәтләрне саклау урыннары өчен имин районнар әзерләү. Күрсәтелгән чараларны үтәүне оештыру законнарда билгеләнгән вәкаләтләр кысаларында җирле үзидарә органнарына йөкләнә;

- эвакуация органнарын төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру, шулай ук аларның шәхси составын әзерләү;

- эвакуация чараларын үткәрүне тәэмин итү өчен транспорт чараларын әзерләү. Күрсәтелгән чараны үтәүне оештыру Саба муниципаль районының транспорт хезмәтенә йөкләнә.»;

**2.3.** 9 пунктның беренче абзацында «хәрби хәрәкәтләр алып барганда яисә шушы гамәлләр нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр һәм террорчылык актлары вакытында» сүзләрен «мобилизация чорында, хәрби хәл гамәлдә булган чорда, сугыш вакытында» сүзләренә алмаштырырга.

**2.4.** 10 пунктның беренче абзацында «хәрби хәрәкәтләр алып барганда яисә шушы гамәлләр нәтиҗәсендә» сүзләрен «мобилизация чорында, хәрби хәл гамәлдә булган чорда, сугыш вакытында»сүзләренә алмаштырырга.;

**2.5.** 10 пунктның сигезенче абзацында «хәрби хәрәкәтләр алып барганда яисә шушы гамәлләр нәтиҗәсендә» сүзләрен «мобилизация чорында, хәрби хәл гамәлдә булган чорда, сугыш вакытында»сүзләренә алмаштырырга.;

**2.6.** 11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Гражданнар оборонасы буенча мобилизация чорында, сугыш хәле гамәлдә булган чорда, сугыш вакытында килеп чыга торган куркынычлар нәтиҗәсендә килеп чыккан янгыннарга каршы көрәшкә бәйле бурычларны хәл итү максатларында гамәлгә ашырыла торган төп чаралар булып түбәндәгеләр тора:

- янгынга каршы кирәкле көчләр булдыру, аларны матди-техник чаралар белән тәэмин итү һәм гражданнар оборонасы өлкәсендә әзерләү;

- һәлакәттән коткару һәм башка кичектергесез эшләр уздырыла торган районнарда янгыннарны сүндерү;

- билгеләнгән тәртиптә гражданнар оборонасы категорияләренә кертелгән объектларда янгыннарны сүндерү.»;

**2.7.** 14 пунктның беренче абзацында «хәрби хәрәкәтләр алып барганда яисә шушы гамәлләр нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр һәм террорчылык актлары нәтиҗәсендә» сүзләрен «мобилизация чорында, хәрби хәл гамәлдә булган чорда, сугыш вакытында»сүзләренә алмаштырырга.

**3.** Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге адрес буенча рәсми рәвештә халыкка җиткерергә: http://pravo.tatarstan.ru.

Башкарма комитет җитәкчесе вазифаларын башкаручы,
инвестицион үсеш комитеты һәм эшмәкәрлеккә ярдәм итү буенча
Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары -
Саба муниципаль районының инвестицион үсеш
һәм эшкуарлыкка ярдәм итү
бүлеге башлыгы И.И. Котдусов